КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 11 февраль № 83

г. Казань

«Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешма уставын раслау һәм «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешманың Попечительләр советы составына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешма эшчәнлеген камилләштерү максатында һәм федераль законнардагы үзгәрешләр нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән түбәндәгеләрне расларга:

«Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешма уставын;

югары коллегиаль орган – «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешма советы составын.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган дәүләт оешмасын төзү турында» 2004 ел, 17 ноябрь, 498 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 17 гыйнвар, 7 нче; 2005 ел, 26 май, 237 нче; 2005 ел, 28 сентябрь, 468 нче; 2005 ел, 28 сентябрь, 469 нчы; 2006 ел, 20 февраль, 66 нчы; 2006 ел, 11 декабрь, 608 нче; 2007 ел, 22 февраль, 65 нче; 2007 ел, 12 ноябрь, 623 нче; 2008 ел, 21 май, 335 нче; 2008 ел, 13 октябрь, 743 нче; 2009 ел, 25 февраль, 103 нче; 2009 ел, 24 март, 166 нчы; 2009 ел, 31 март, 193 нче; 2010 ел, 11 август, 639 нчы; 2011 ел, 25 март, 230 нчы; 2012 ел, 31 август, 741 нче; 2014 ел, 11 март, 152 нче; 2014 ел, 26 ноябрь, 195 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешманың Попечительләр советы составына, аны яңа редакциядә бәян итеп (теркәлгән), үзгәрешләр кертергә.

3. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган дәүләт оешмасын төзү турында» 2004 ел, 17 ноябрь, 498 нче карарына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 11 август, 639 нчы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган дәүләт оешмасын төзү турында» 2004 ел, 17 ноябрь, 498 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган дәүләт оешмасының попечительләр советы составына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 ел, 25 март, 230 нчы карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 31 август, 741 нче карарының 2 пункты;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган дәүләт оешмасы исемен үзгәртү һәм «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасы уставын раслау турында» 2013 ел, 6 март, 149 нчы карарының 2 пункты;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 11 март, 152 нче карарының 2 пункты;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган дәүләт оешмасын төзү турында» 2004 ел, 17 ноябрь, 498 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган дәүләт оешмасының попечительләр советы составына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 ел, 26 ноябрь, 915 нче карары.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\83.docx

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 11 февраль, 83 нче карары белән расланды

**«Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешма уставы**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешма (алга таба – Фонд) фонд рәвешендәге унитар коммерциягә карамаган оешма булып тора.

1.2. Фондның тулы исеме: «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешма.

Фондның кыскартылган исеме: «ТР ИВФ» ККО.

Фондның инглиз телендә тулы исеме: Non-Profit Organization «Investment and Venture Fund of the Republic of Tatarstan».

Фондның инглиз телендә кыскартылган исеме: IVF RT.

1.3. Фондның урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Казан шәһәре.

1.4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Фондның гамәлгә куючысы булып тора (алга таба – Гамәлгә куючы).

1.5. Фонд дәүләт теркәвенә алынган вакыттан соң юридик зат була, милкендә аерымланган мөлкәте була һәм үз йөкләмәләре буенча аларга җавап бирә (законнарда билгеләнгән очраклардан тыш), үз исеменнән мөлкәт һәм мөлкәт булмаган хокуклар сатып ала һәм аларны гамәлгә ашыра, граждан бурычларын җавап бирә, судта дәгъвачы һәм җавап бирүче була ала.

1.6. Фондның мөстәкыйль балансы, кредит оешмаларында исәп-хисап, валюта һәм башка счетлары, фирма бланкы, Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә Фондның тулы исеме һәм Татарстан Республикасы Дәүләт гербы сурәте белән мөһере һәм башка мөһерләре бар.

1.7. Фонд Россия Федерациясе законнары нигезендә Россия Федерациясе территориясендә филиаллар төзергә һәм вәкиллекләр ачырга хокуклы.

Вәкиллекләр һәм филиаллар юридик затларның бердәм дәүләт реестрында күрсәтелергә тиеш.

1.8. Әлеге Уставта каралган максатларга ирешү мәнфәгатьләрендә Фонд хуҗалык җәмгыятьләре төзергә һәм аларда катнашырга хокуклы, шулай ук башка коммерциягә карамаган оешмалар төзергә һәм ассоциацияләргә һәм берлекләргә керә ала.

1.9. Фонд законнарда тыелмаган теләсә кайсы формада халыкара, чит ил һәм бүтән оешмалар эшчәнлегендә катнашырга һәм хезмәттәшлек итәргә хокуклы.

1.10. Фонд үз эшчәнлеген мөстәкыйль планлаштыра, законнарда билгеләнгән тәртиптә эшләү өчен россия һәм чит ил белгечләрен җәлеп итәргә хокуклы.

1.11. Фонд Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында

каралган бүтән гамәлләрне кылырга хокуклы.

## 2. Фонд эмблемалары

2.1. Фондның дүрт эмблемасы бар, алар үзара элементларның рәсем һәм сүз белән чагылдырылган катнаш комбинацияләре булып тора.

2.2. Беренче эмблема.

Эмблеманың рәсеме үз эченә өч түгәрәк алган зәңгәр төстәге түгәрәк формадагы билгедән гыйбарәт.

Кече түгәрәк уртасында ачык сары төстәге рәсем элемент урнашкан, ул очлы почмак белән бер-берсенә күчә торган бер стильдәге ике кул рәсеменнән гыйбарәт. Моннан тыш рәсем элементы астында эмблеманың сүзләр белән аңлатмасы язылган, ул эмблеманың хуҗасы IVF RT (рус теленә тәрҗемәсе ИВФ РТ) булуын күрсәтә торган инглиз телендәге ачык сары төстәге текстны тәшкил итә.

Урта түгәрәк әйләнәсенең эчке ягы буенча эмблеманың сүзләр белән мәгънәсе урнашкан, ул инглиз телендәге ачык сары төстәге текстны тәшкил итә, эмблеманың хуҗасына күрсәтә: INVESTMENT AND VENTURE FUND OF THE REPUBLIC OF TATARSTAN (рус теленә тәрҗемәсе – ИНВЕСТИЦИОННО-ВЕНЧУРНЫЙ ФОНД РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН). «INVESTMENT» (рус теленә тәрҗемәсе – ИНВЕСТИЦИОННО) һәм «TATARSTAN» (рус теленә тәрҗемәсе – ТАТАРСТАН) сүзләре арасында ачык сары төстә эре нокта урнаштырылган.

2.3. Икенче эмблема.

Эмблеманың рәсеме үз эченә өч түгәрәк алган зәңгәр төстәге түгәрәк формадагы билгедән гыйбарәт.

Кече түгәрәк уртасында ачык сары төстәге рәсем элемент урнашкан, ул очлы почмак белән бер-берсенә күчә торган бер стильдәге ике кул рәсеменнән гыйбарәт. Моннан тыш рәсем элементы астында эмблеманың сүзләр белән аңлатмасы язылган, ул эмблеманың хуҗасы ИВФ РТ булуын күрсәтә торган рус телендәге ачык сары төстәге текстны тәшкил итә.

Урта түгәрәк әйләнәсенең эчке ягы буенча эмблеманың сүзләр белән мәгънәсе урнашкан, ул рус телендәге ачык сары төстәге текстны тәшкил итә, эмблеманың хуҗасына күрсәтә: ИНВЕСТИЦИОННО-ВЕНЧУРНЫЙ ФОНД РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН. «ИНВЕСТИЦИОННО» һәм «ТАТАРСТАН» сүзләре арасында ачык сары төстә эре нокта урнаштырылган.

2.4. Өченче эмблема.

Эмблеманың рәсеме үз эченә өч түгәрәк алган зәңгәр төстәге түгәрәк формадагы билгедән гыйбарәт.

Кече түгәрәк уртасында ак төстәге рәсем элемент урнашкан, ул очлы почмак белән бер-берсенә күчә торган бер стильдәге ике кул рәсеменнән гыйбарәт. Моннан тыш рәсем элементы астында эмблеманың сүзләр белән аңлатмасы язылган, ул эмблеманың хуҗасы ИВФ РТ булуын күрсәтә торган рус телендәге ак төстәге текстны тәшкил итә.

Урта түгәрәк әйләнәсенең эчке ягы буенча эмблеманың сүзләр белән мәгънәсе урнашкан, ул рус телендәге ак төстәге текстны тәшкил итә, эмблеманың хуҗасына

күрсәтә: ИНВЕСТИЦИОННО-ВЕНЧУРНЫЙ ФОНД РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН. «ИНВЕСТИЦИОННО» һәм «ТАТАРСТАН» сүзләре арасында ак төстә эре нокта урнаштырылган.

2.5. Дүртенче эмблема.

Эмблеманың рәсеме үз эченә өч түгәрәк алган ак төстәге түгәрәк формадагы билгедән гыйбарәт.

Кече түгәрәк уртасында зәңгәр төстәге рәсем элемент урнашкан, ул очлы почмак белән бер-берсенә күчә торган бер стильдәге ике кул рәсеменнән гыйбарәт. Моннан тыш рәсем элементы астында эмблеманың сүзләр белән аңлатмасы язылган, ул эмблеманың хуҗасы ИВФ РТ булуын күрсәтә торган рус телендәге зәңгәр төстәге текстны тәшкил итә.

Урта түгәрәк әйләнәсенең эчке ягы буенча эмблеманың сүзләр белән мәгънәсе урнашкан, ул рус телендәге зәңгәр төстәге текстны тәшкил итә, эмблеманың хуҗасына күрсәтә: ИНВЕСТИЦИОННО-ВЕНЧУРНЫЙ ФОНД РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН. «ИНВЕСТИЦИОННО» һәм «ТАТАРСТАН» сүзләре арасында зәңгәр төстә эре нокта урнаштырылган.

## 3. Фондның төп максатлары, бурычлары һәм вазыйфалары

3.1. Фонд эшчәнлегенең максатлары һәм предметы булып Татарстан Республикасының инновация потенциалын күтәрү, фән сыйдырышлы производстволарны һәм яңа прогрессив технологияләрне гамәлгә кертү тора. Фонд фәнни, фәнни-техник эшчәнлеккә, инновация эшчәнлегенә булышлык күрсәтү фонды булып тора.

3.2. Фондның төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

инновация эшчәнлегенә булышлык күрсәтү, яңа төр продукция һәм технологияләр җитештерүне өйрәнү;

фәнни-техник продукция базарын формалаштыруда катнашу;

Татарстан Республикасы икътисадының өстенлекле тармакларын үстерү;

Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык күрсәтү;

Татарстан Республикасының инвестиция сәясәте өстенлекләренә җавап бирә торган инвестиция ягыннан кызыклы проектларга инвестиция һәм венчур капиталын җәлеп итү;

венчур индустриясенең финанс һәм инфраструктур элементларын булдыруда һәм инвестицияләүдә катнашу;

Татарстан Республикасының инвестиция потенциалын күтәрү максатында күргәзмә эшчәнлеген гамәлгә ашыру.

3.3. Үз бурычларын гамәлгә ашыру өчен Фонд:

3.3.1. Татарстан Республикасы икътисадының өстенлекле тармакларында инновация һәм (яки) инвестиция программаларын һәм проектларын эшләүдә, конкурс нигезендә сайлап алуда һәм аларга экспертизада катнаша;

3.3.2. Инновация һәм (яки) инвестиция программаларын һәм проектларын түбәндәгеләр аша финанслауны гамәлгә ашыра:

башка оешмаларда катнашу (өлешләр, акцияләр, пайлар сатып алу юлы

белән);

өлешләр, акцияләр, пайлардан инвестиция чаралары алу һәм аларны тормышка ашырыла торган проектларны алга таба инвестицияләүгә юнәлтү;

мөлкәтне кыйммәтле кәгазьләргә һәм бүтән объектларга инвестицияләү;

мөлкәтне инвестиция пайлары алу өчен файдалану;

проектларны тормышка ашыруга максатлы заемнар, шул исәптән процентсыз, бирү;

кредит оешмалар кредитлары буенча процентларның бер өлешенә компенсация бирү;

законнарда тыелмаган башка ысуллар;

3.3.3. Бизнес-инкубаторлар, технопарклар һәм Татарстан Республикасы инновация инфрастуктурасының бүтән элементларын төзүне һәм үстерүне финанслый;

3.3.4. Коммерция ягыннан өметле булган инновация компанияләренә ярдәм күрсәтүне түбәндәге юллар белән гамәлгә ашыра:

төгәл фәнни, фәнни-техник программаларны һәм проектларны, инновация проектларын максатлы финанслау;

фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструктор эшләнмәләрен финанслау;

акселерация программалары һәм башка инновация проектларына ярдәм күрсәтү программалары аша инновация проектларына ярдәм күрсәтү программаларын финанслау;

коммерция ягыннан өметле булган фәнни тикшеренүләрнең республика һәм федераль конкурсларны оештыруда һәм финанслауда катнашу;

3.3.5. Конгресс-форум, күргәзмә-ярминкә һәм башка чараларда катнашу һәм аларны финанслау юлы белән инновация продукциясе һәм технологияләрен алга чыгаруны гамәлгә ашыра;

3.3.6. Фондның устав бурычларын хәл итүгә юнәлтелгән бүтән эшчәнлекне гамәлгә ашыра.

3.4. Фонд әлеге Уставта билгеләнгән максатларга ярашлы һәм Фондның төзелү максаты булган һәм әлеге максатларга ярашлы иҗтимагый файдалы максатларга ирешү өчен кирәкле эшмәкәрлек эшчәнлеге яки табыш китерүче бүтән эшчәнлек белән шөгыльләнергә хокуклы.

## 4. Фонд мөлкәте

4.1. Фондка аның гамәлгә куючысы тапшырган мөлкәт фонд милкендә була. Әлеге Уставның 3.1 пунктында билгеләнгән максатлар нигезендә Фондның үз милкендә булган мөлкәткә хуҗа булу, аннан файдалану һәм аның белән эш итү хокуклары була.

4.2. Фондның гамәлгә куючысы үзе төзегән Фондка мөнәсәбәттә мөлкәт хокукларына ия булмый. Гамәлгә куючысы үзе төзегән Фонд йөкләмәләре буенча җавап тотмый, ә Фонд үзенең гамәлгә куючысы йөкләмәләре буенча җавап тотмый.

4.3. Фондның гамәлгә куючысы үзе Фонд милкенә тапшырган мөлкәткә хокукларын югалта. Фондны бетергән очракта аның кредиторлар таләпләрен канәгатьләндергәннән соң калган мөлкәте әлеге Уставта күрсәтелгән максатларда

кулланыла.

4.4. Фонд мөлкәтен формалаштыру чыганаклары түбәндәгеләр:

гамәлгә куючыдан даими һәм бер тапкыр кергән акча;

ирекле мөлкәти кертемнәр һәм иганә акчасы;

сатылган товарлардан, эшләрдән, хезмәтләрдән табыш;

акцияләр, облигацияләр, башка кыймммәтле кәгазьләрдән һәм салып куелган акчалардан алына торган дивидентлар (керемнәр, процентлар)

Фонд милкен куллануда алына торган табышлар;

әлеге Уставның 3.3.2 пункты нигезендә инвестиция чаралары керү;

законнарда тыелмаган башка керемнәр.

4.5. Фонд ел саен үзенең мөлкәтен файдалану турында хисапларны «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге ivf.tatarstan.ru сайтында бастырырга тиеш.

4.6. Фонд штатын тоту Фонд акчасы исәбеннән, шул исәптән эшмәкәрлек эшчәнлегеннән алынган табышлар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

## 5. Фонд органнары структурасы

5.1. Фонд органнары структурасы түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Попечительләр советы,

югары коллегиаль орган – Совет;

башкарма органнар:

коллегиаль башкарма орган – Инвестиция комитеты,

бер заттан гыйбарәт башкарма орган – директор.

5.2. Фонд органнары әгъзалары Фонд эшчәнлегенә һәм аның органнарына мөнәсәбәттә конфиденциальлек сакларга тиеш.

## 6. Попечительләр советы

6.1. Попечительләр советы Фонд эшчәнлегенә, Фондның башка органнары тарафыннан карарлар кабул итү һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә, Фонда акчаларын файдалануга, Фондың законнарны үтәвенә күзәтчелекне гамәлгә ашыра торган орган булып тора. Попечительләр советы үз эшчәнлеген имҗтимагый башлангычларда тормышка ашыра.

6.2. Попечительләр советының шәхси составын Фондның Гамәлгә куючысы раслый. Попечительләр советы составына Попечительләр советы рәисе сыйфатында үз теләге белән Татарстан Республикасы Президенты керә ала.

Фондның Попечительләр советына Фондның гамәлгә куючысы вәкилләре, Татарстан Республикасы башкарма хакимият һәм җирле үзидарә органнары вәкилләре, инвесторлар, россия һәм халыкара инновация җәмгыятьләренең актив катнашучылары керә ала.

Фонд органнары составына керүче затлар Попечительләр советы әгъзалары була алмый.

Попечительләр советы вәкаләтләренең вакыты чикләнми.

6.3. Попечительләр советы компетенциясенә түбәндәгеләр карый:

Фонд эшчәнлегенә, Фондның башка органнары тарафыннан карарлар кабул итү һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә, Фонда акчаларын файдалануга, Фондың законнарны үтәвенә күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

Фонд Советы һәм Фондның башкарма органнары хисапларын карап тикшерү;

Фонд эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрүгә булышлык итүче күзәтчелек чараларын үткәрү;

законнарда каралган бүтән вәкаләтләр.

6.4. Попечительләр советын аның рәисе җитәкли.

Попечительләр советы әгъзалары түбәндәгеләргә хокуклы:

Попечительләр советы утырышларында катнашырга;

Фонд үткәрә һәм (яки) тормышка ашыра торган чараларда һәм программаларда катнашырга;

Фонд органнары каравына Фонд эшчәнлеге буенча тәкъдимнәр кертергә;

Фонд эшчәнлеге турында хисаплар таләп итәргә;

Фонд идеяләрен популярлаштыру һәм Фондның төп максатларына ирешү өчен акча җәлеп итү максатларында Фонд символларын, аның эмблемаларын кулланырга;

Попечительләр советы эшендә катнашу белән турыдан-туры бәйле чыгымнарга компенсация алырга;

Попечительләр советы рәисе исеменә Попечительләр советы эшендә үзенең катнашуын туктату теләге турында гариза бирү юлы белән теләсә кайсы вакытта Попечительләр советында әгъза булудан туктарга.

6.5. Попечительләр советы әгъзалары бурычлары түбәндәгеләр:

Фонд максатларына ирешүдә һәм эшчәнлеге мәсьәләләрен хәл итүдә шәхсән катнашу;

Фондка гражданнардан һәм юридик затлардан ирекле иганә акчасы, инвестицияләр һәм кертемнәр, шулай ук бүтән финанс инструментларын җәлеп итүдә булышлык күрсәтү;

Фонд эшчәнлеге турында мәгълүматның таралуына булышлык күрсәтү;

Фонд программаларын тормышка ашыруда төрле яклап булышлык күрсәтү;

Фонд акчасын файдалануга һәм Фонд тарафыннан законнарны үтәүгә, шулай ук Фондның башка органнары тарафыннан карарлар кабул итүгә аларны куллануга Попечительләр советы күзәтчелеген гамәлгә ашыруны тәэмин итү.

6.6. Попечительләр советы утырышлары кирәк булган саен, кимендә елга бер тапкыр үткәрелә.

6.7. Попечительләр советы утырышын чакыру һәм үткәрү турында карарны Попечительләр советы рәисе үз башлангычы белән яки Попечительләр советы, Совет әгъзаларының берсе, шулай ук директор гаризасы буенча кабул итә.

6.8. Попечительләр советы әгъзаларына Попечительләр советы утырышын чакыру һәм үткәрү турында аны үткәрү көненә кадәр биш календарь көненнән дә соңга калмый хәбәр ителә.

Попечительләр советы утырышын чакыру һәм үткәрү турында хәбәр итү почта, телеграф, телетайп, телефон, электрон элемтә аша яки тапшырыла һәм кабул ителә торган мәгълүматларның дөреслеген һәм аларны документлар белән раслауны

тәэмин итә торган элемтә аша гамәлгә ашырыла яисә Попечительләр советы әгъзасына шәхси имзасы куелып тапшырыла.

Хәбәрнамәдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

Попечительләр советы утырышын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

Попечительләр советы утырышының көн тәртибе.

Хәбәрнамәгә көн тәртибе мәсьәләләре буенча барлык кирәкле материаллар теркәлә.

6.9. Утырышны Попечительләр советы рәисе, ул катнаша алмаганда Попечительләр советы рәисе урынбасары үткәрә.

6.10. Попечительләр советы утырышы, читтән торып тавыш бирү, әгәр анда әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, тулы хокуклы була (кворумга ия була). Попечительләр советы утырышында мәсьәләләрне хәл иткәндә һәр әгъза бер тавышка ия. Попечительләр советы әгъзасы тавыш бирү хокукын бүтән затка, шул исәптән Попечительләр советының башка әгъзасына тапшыру рөхсәт ителми.

6.11. Попечительләр советы утырышында карарлар ачык тавыш бирү белән, утырышта катнашучы Попечительләр советы әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Карарлар кабул иткәндә Попечительләр советы әгъзалары тавышы тигез булган очракта Попечительләр советы рәисе хәлиткеч тавыш хокукына ия. Тавыш биргәндә азчылыкта калган Попечительләр советы әгъзалары фикере алар таләбе буенча беркетмәгә кертелә.

6.12. Попечительләр советы утырышында рәислек итүче беркетмәне алып баруны оештыра.

Кабул ителгән карарлар Попечительләр советы утырышын үткәрү турында хәбәрнамә өчен каралган тәртиптә беркетмә төзелгәннән соң биш календарь көненнән соңга калмый табыш бирү йомгаклары турында хисап рәвешендә Попечительләр советы әгъзаларына җиткерелә.

6.13. Попечительләр советы карары аның утырышын үткәрмичә генә, читтән торып тавыш бирү юлы белән кабул ителергә мөмкин.

Читтән торып тавыш бирү үткәрү турында хәбәр итү бюллетеньдә күрсәтелгән аны кабул итү вакытына кадәр 10 көн алдан почта, телеграф, телетайп, телефон, электрон элемтә аша яки тапшырыла һәм кабул ителә торган мәгълүматларның дөреслеген һәм аларны документлар белән раслауны тәэмин итә торган элемтә аша гамәлгә ашырыла яисә Попечительләр советы әгъзасына шәхси имзасы куелып тапшырыла.

Хәбәрнамәгә мәҗбүри тәртиптә көн тәртибе мәсьәләләре буенча барлык кирәкле материаллар, шулай ук читтән торып тавыш бирү өчен бюллетень (алга таба – бюллетень) беркетелә. Бюллетеньдә бюллетеньне кабул итү вакыты, аны җибәрергә кирәк булган урын, көн тәртибе, тавыш бирүгә куелган сораулар, алар буенча карарлар проектлары беркетелә.

Читтән торып тавыш бирү рәвешендә Попечительләр советы карарлары:

тавыш бирүдә катнашкан Попечительләр советы әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә;

читтән торып тавыш бирү турында хәбәрнамә өчен каралган тәртиптә читтән торып тавыш бирү нәтиҗәләре хакында беркетмә төзегәннән соң биш календарь

көненнән дә соңга калмый тавыш бирү йомгаклары турында хисап рәвешендә Попечительләр советы әгъзаларына җиткерелә.

6.14. Попечительләр советы утырышы беркетмәсе (читтән торып тавыш бирү нәтиҗәләре турында беркетмә) утырыш үткәрелгән (бюллетеньнәрне кабул итү вакыты тәмамланган) көннән соң өч эш көненнннән соңга калмыйча ике нөсхәдә төзелә. Ике нөсхәгә дә Попечительләр советы утырышында рәислек итүче һәм секретарь тарафыннан имза куела. Беркетмәләр Попечительләр советы секретарында һәм фондта саклана.

6.15. Попечительләр советы утырыш беркетмәсендә (читтән торып тавыш бирү нәтиҗәләре турында беркетмәдә) түбәндәгеләр күрсәтелә:

утырышны үткәрү датасы, урыны һәм вакыты (читтән торып тавыш бирү өчен – бюллетень кабул итүнең соңгы датасы);

тавыш бирүдә катнашкан Попечительләр советы әгъзаларының гомуми саны һәм алар турында белешмәләр;

Попечительләр советы утырышында катнашучы затлар (урында тавыш бирү өчен);

көн тәртибе һәм көн тәртибенең һәр мәсьәләсе буенча тавыш бирү нәтиҗәләре;

тавышларны санаган зат (секретарь) турында белешмәләр;

беркетмәгә имза куйган затлар турында белешмәләр;

Попечительләр советы карарын кабул итүгә каршы тавыш биргән һәм бу хакта беркетмәгә язуны таләп иткән Попечительләр советы әгъзалары турында белешмәләр.

## 7. Югары коллегиаль орган – Совет

7.1. Фондның югары коллегиаль органы булып Совет тора. Совет үз эшчәнлеген иҗтимагый башлангычларда гамәлгә ашыра.

Советның төп вазыйфасы – Фонд тарафыннан үзе төзелгән максатларны саклауны тәэмин итү.

7.2. Советның шәхси составын Фондны Гамәлгә куючы раслый. Вазыйфа буенча Совет составына аның рәисе булган Татарстан Республикасы Премьер-министры һәм Совет секретаре булган директоры керә. Совет вәкаләтләренең вакыты чикләнмәгән.

7.3. Совет компетенциясенә түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү карый:

Фонд эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләрен, аның мөлкәтен оештыру һәм файдалану принципларын билгеләү;

Фонд Уставына үзгәрешләр кертүне килештерү;

Фонд органнарын формалаштыру һәм аларның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату;

Фондның еллык хисабын һәм бухгалтер (финанс) хисаплылыгын раслау;

Фонд тарафыннан башка юридик затлар төзү турында, Фондның башка юридик затларда катнашуы хакында, Фондның филиалларын төзү һәм вәкиллекләрен ачу турында карарлар кабул итү;

Фондның аудитор оешмасын яки шәхси аудиторын раслау;

Фондның финанс планын раслау һәм аңарга үзгәрешләр кертү;

бәясе Фонд активларының соңгы хисап датасына бухгалтер хисаплыгы мәгълүматлары буенча билгеләнгән баланс кыйммәтенең 20 проценттан артыгын тәшкил иткән проектларга инвестицияләү буенча килешүләр яки берничә үзара бәйләнгән килешүләр төзүне килештерү;

проектларга инвестицияләү буенча булмаган килешүләр яки берничә үзара бәйләнгән килешүләр төзүне килештерү, әгәр мондый килешүләрне төзү Фондның башкарма органнары компетенциясенә карамаса:

конгресс-форум, күргәзмә-ярминкә чараларын, рәсми делегацияләр визитларын һәм башкаларны финанслау;

Совет рәисе тәкъдиме белән килешүләрне хуплау.

Әлеге пунктның икенче – җиденче абзацларында каралган мәсьәләләр Советның чыгарылма компетенциясенә карый.

7.4. Совет әгъзалары түбәндәгеләргә хокуклы:

Совет утырышларында катнашырга;

Фонд үткәрә һәм (яки) тормышка ашыра торган чараларда һәм программаларда катнашырга;

Фонд карап тикшерүенә Фонд эшчәнлеге мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр кертергә;

Фонд эшчәнлеге турында Фондның башкарма органнары хисабын таләп итергә;

Совет эшендә катнашу белән турыдан-туры бәйле чыгымнарга компенсация алырга;

Фонд Советы рәисе исеменә Совет эшендә катнашуын туктау теләге барлыгы турында гариза бирү юлы белән теләсә кайсы вакытта Совет әгъзасы булудан туктарга.

7.5. Совет әгъзалары бурычлары түбәндәгеләр:

Фонд эшчәнлеге максатларына ирешүдә һәм бурычларын хәл итүдә шәхси катнашу;

Фондка гражданнардан һәм юридик затлардан ирекле иганә акчасы һәм кертемнәр җәлеп итүгә булышлык итү;

Фонд эшчәнлеге турында мәгълүмат таратуга булышлык итү;

Фонд программаларын һәм проектларын тормышка ашыруда бөтен яклап ярдәм күрсәтү.

7.6. Совет утырышлары зарур булганда үткәрелә.

7.7. Советны чакыру һәм утырышын үткәрү турында карарны Совет рәисе үз инициативасы белән, Совет, шулай ук фондның башкарма органнары әгъзаларының берсе гаризасы буенча кабул итә.

7.8. Совет әгъзаларына Советны чакыру һәм утырышын үткәрү турында аны үткәрүгә кадәр биш календарь көне алдан хәбәр ителә.

Советны чакыру һәм утырышын үткәрү турында хәбәр итү заказлы хатлар, телеграммалар, телефонограммалар юллау юлы белән, электрон, факсимиль элемтә һәм кабул ителә торган мәгълүматларның дөреслеген һәм аларны документлар белән раслауны тәэмин итә торган бүтән элемтә аша җибәрелә яисә Совет әгъзасына шәхси имзасы куелып тапшырыла.

Хәбәрнамәдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

Совет утырышын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

Совет утырышының көн тәртибе.

Хәбәрнамәгә көн тәртибе мәсьәләләре буенча барлык кирәкле материаллар теркәлә.

7.9. Утырышны Совет рәисе, ул катнаша алмаганда аның урынбасары үткәрә.

7.10. Совет утырышы, әгәр анда әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, тулы хокуклы була.

Совет утырышында мәсьәләләрне хәл иткәндә һәр әгъза бер тавышка ия. Совет әгъзасы тавыш бирү хокукын бүтән затка, шул исәптән Советның башка әгъзасына тапшыру рөхсәт ителми.

7.11. Совет утырышы (читтән торып тавыш бирү), әгәр анда әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, тулы хокуклы була.

Күрсәтелгән утырыш (читтән торып тавыш бирү), утырышта катнашучы (читтән торып тавыш бирүдә катнашучы) әгъзаларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Советның чыгарма компетенциясе мәсьәләләре буенча утырыш карары Совет әгъзалары тавышының гомуми санының өчтән икесеннән ким булмаган махсус күпчелек тавыш белән кабул ителә.

7.12. Совет утырышында рәислек итүче беркетмә алып баруны оештыра.

Кабул ителгән карарлар Совет утырышын үткәрү турында хәбәрнамә өчен каралган тәртиптә беркетмә төзелгәннән соң биш календарь көненнән соңга калмый табыш бирү йомгаклары турында хисап рәвешендә Совет әгъзаларына җиткерелә.

7.13. Совет карары аның утырышын үткәрмичә генә, читтән торып тавыш бирү (сораштыру юлы) белән кабул ителергә мөмкин, әлеге Уставның 7.3 пунктындагы икенче – җиденче абзацларда каралган мәсьәләләр буенча карарлар кабул итүдән тыш. Мондый тавыш бирү почта, телеграф, телетайп, телефон, электрон элемтә аша яки тапшырыла һәм кабул ителә торган мәгълүматларның дөреслеген һәм аларны документлар белән раслауны тәэмин итә торган элемтә аша гамәлгә ашырыла торган документлар алмашу юлы белән үткәрелә ала.

Читтән торып тавыш бирү үткәрү турында хәбәр итү бюллетеньдә күрсәтелгән аны кабул итү вакытына кадәр (тавыш бирү процедурасы тәмамланганга кадәр) 10 көн алдан почта, телеграф, телетайп, телефон, электрон элемтә аша яки тапшырыла һәм кабул ителә торган мәгълүматларның дөреслеген һәм аларны документлар белән раслауны тәэмин итә торган элемтә аша гамәлгә ашырыла яисә Совет әгъзасына шәхси имзасы куелып тапшырыла.

Хәбәрнамәгә мәҗбүри тәртиптә көн тәртибе мәсьәләләре буенча барлык кирәкле материаллар, шулай ук читтән торып тавыш бирү өчен бюллетень беркетелә. Бюллетеньдә бюллетеньне кабул итү вакыты, аны җибәрергә кирәк булган урын, көн тәртибе, тавыш бирүгә куелган сораулар, алар буенча карарлар проектлары беркетелә. Хәбәрнамәдә тавыш бирү башланганчы Советның барлык әгъзаларын барлык кирәкле мәгълүмат һәм материаллар белән таныштыру тәртибе, көн тәртибенә өстәмә мәсьәләләр кертү турында тәкъдимнәрне кертү мөмкинлеге, үзгәргән көн тәртибенә тавыш бирү башланганчы Советның барлык әгъзаларына хәбәр итү мәҗбүрилеге булырга тиеш.

Читтән торып тавыш бирү рәвешендә Совет карарлары:

тавыш бирүдә катнашкан әгъзаларның гади күпчелек тавышы белән, чыгарма компетенция мәсьәләләре буенча тавыш бирүдә катнашкан әгъзалар тавышының гомуми санының өчтән икесеннән ким булмаган махсус күпчелек тавыш белән кабул ителә;

читтән торып тавыш бирү турында хәбәрнамә өчен каралган тәртиптә читтән торып тавыш бирү нәтиҗәләре хакында беркетмә төзегәннән соң биш календарь көненнән дә соңга калмый тавыш бирү йомгаклары турында хисап рәвешендә Совет әгъзаларына җиткерелә.

7.14. Совет утырышы беркетмәсе (читтән торып тавыш бирү нәтиҗәләре турында беркетмә) утырыш үткәрелгән (бюллетеньнәрне кабул итү вакыты тәмамланган) көннән соң өч эш көненнннән соңга калмыйча төзелә. Беркетмәгә Совет утырышында рәислек итүче һәм секретарь тарафыннан имза куела. Беркетмәләр Совет секретарында һәм фондта саклана.

7.15. Совет утырышы беркетмәсендә (читтән торып тавыш бирү нәтиҗәләре турында беркетмәдә) түбәндәгеләр күрсәтелә:

утырышны үткәрү датасы, урыны һәм вакыты (читтән торып тавыш бирү өчен – бюллетень кабул итүнең соңгы датасы);

тавыш бирүдә катнашкан Совет әгъзаларының гомуми саны һәм алар турында белешмәләр;

утырышта катнашучы затлар (урында тавыш бирү өчен);

көн тәртибе һәм көн тәртибенең һәр мәсьәләсе буенча тавыш бирү нәтиҗәләре;

тавышларны санаган зат (секретарь) турында белешмәләр;

беркетмәгә имза куйган затлар турында белешмәләр;

Совет карарын кабул итүгә каршы тавыш биргән һәм бу хакта беркетмәгә язуны таләп иткән Совет әгъзалары турында белешмәләр.

## 8. Фондның башкарма органнары

8.1. Фондта түбәндәге башкарма органнар гамәлдә була:

коллегиаль орган – Инвестиция комитеты;

бер затлы орган – директор.

Башкарма органнар Фонд эшчәнлегенә агымдагы җитәкчелекне гамәлгә ашыра һәм Советка хисап тота.

8.2. Инвестиция комитеты биштән азрак һәм 11 дән күрбәк булмаган кеше составында Совет тарафыннан сайлана. Инвестиция комитеты рәисе директор була, ул, үз чиратында, Совет секретаре булып тора. Инвестиция комитеты вәкаләтләре вакыты чикләнми.

8.3. Инвестиция комитеты үз эшчәнлеген Совет раслаган Инвестиция комитеты турында нигезләмәдә каралган тәртиптә төзи.

8.4. Инвестиция комитеты компетенциясенә түбәндәге мәсьәләләр карый:

инвестиция иптәшлегендә катнашу;

Фонд мөлкәтен кыйммәтле кәгазьләргә һәм бүтән объектларга инвестицияләү;

Фонд мөлкәтен инвестиция пайларын сатып алу өчен файдалану;

инвестиция чараларын алу һәм аларны акцияләр, өлешләр, пайлар сату-алу юлы белән тормышка ашырыла торган проектларны инвестицияләүгә юнәлдерү;

проектларга инвестицияләү белән бәйле килешү яки берничә үзара бәйләнгән килешүләр төзүне хуплау, Совет рәисе Совет хуплавына чыгарган килешүләрдән тыш;

финанс гарантияләре бирү;

максатлы заемнар бирү, шул исәптән процентсыз;

максатлы финанслау бирү;

заем буенча бурычны реструктуризацияләү (процент нормаларын үзгәртү, пролонгация, штраф санкцияләрен бетерү һәм займ шартнамәсе шартларын башкача үзгәртүләр);

хокукларны (таләпләрне) сатып алу һәм киметү, бурычны сатып алу һәм күчерү;

Фондның инвестиция куркынычы булган башка килешүләрдә катнашуы.

Инвестиция комитеты әлеге мәсьәләләр буенча Инвестиция комитеты турында нигезләмә, шулай ук Фондның башка локаль норматив актлары кысаларында карарлар кабул итәргә хокуклы. Бу чакта әгәр карала торган килешүнең суммасы Фонд активларының соңгы хисап датасына бухгалтер мәгълүматлары белән билгеләнгән баланс кыйммәтенең 20 проценттан артык булмаган өлешен тәшкил итсә, Инвестиция комитеты әлеге мәсьәләләр буенча карарлар кабул итәргә вәкаләтле.

8.5. Инвестиция комитеты утырышлары кирәк булганда үткәрелә.

8.6. Инвестиция комитетын чакыру һәм утырышын үткәрү турында карарны Инвестиция комитеты рәисе үз инициативасы белән яки Инвестиция комитеты әгъзаларының берсе гаризасы буенча кабул итә.

8.7. Инвестиция комитеты әгъзаларына Инвестиция комитетын чакыру һәм утырышын үткәрү турында аны үткәрүгә кадәр биш календарь көне алдан хәбәр ителә. Инвестиция комитеты чакыру һәм утырышын үткәрү турында хәбәр итү почта, телеграф, телетайп, телефон, электрон элемтә аша яки тапшырыла һәм кабул ителә торган мәгълүматларның дөреслеген һәм аларны документлар белән раслауны тәэмин итә торган элемтә аша гамәлгә ашырыла яисә Инвестиция комитеты әгъзасына шәхси имзасы куелып, тавыш бирү өчен бюллетеньнәрне теркәп, тапшырыла.

8.8. Инвестиция комитеты утырышлары бергә катнашу юлы яисә читтән торып тавыш бирү юлы белән үткәрелә. Инвестиция комитеты утырышына катнашмаган Инвестиция комитеты әгъзасының кворум барлыгын һәм тавыш бирү нәтиҗәләрен билгеләгәндә көн тәртибе мәсьәләләре буенча язмача фикерен исәпкә алу рөхсәт ителә. Инвестиция комитеты әгъзалары Инвестиция комитеты утырышларында тавыш бирүдә конференцэлемтә аша һәм Инвестиция комитеты утырышында катнашучылар берсен берсе ишетергә мөмкинлек бирә торган теләсә кайсы элемтә җайланмасы ярдәмендә катнашырга хокуклы

8.9. Инвестиция комитеты утырышы, читтән торып тавыш бирү, әгәр анда әгъзаларының өчтән икесе катнашса, тулы хокуклы санала.

8.10. Һәр мәсьәлә буенча карар Инвестиция комитеты әгъзалары тавышының гомуми санының өчтән икесеннән ким булмаган махсус күпчелек тавыш белән кабул ителә.

Кабул ителгән карарлар тавыш бирү йомгаклары турында хисап рәвешендә Инвестиция комитеты утырышын үткәрү турында хәбәрнамәдә каралган тәртиптә беркетмә төзелгәннән соң биш календарь көненнән соңга калмый тавыш бирү йомгаклары турында хисап рәвешендә Инвестиция комитеты әгъзаларына җиткерелә.

8.11. Читтән торып тавыш бирү рәвешендә Инвестиция комитеты утырышын үткәрү турында хәбәр итү бюллетеньдә күрсәтелгән аны кабул итү вакытына кадәр 10 көн алдан почта, телеграф, телетайп, телефон, электрон элемтә аша яки тапшырыла һәм кабул ителә торган мәгълүматларның дөреслеген һәм аларны документлар белән раслауны тәэмин итә торган элемтә аша гамәлгә ашырыла яисә Инвестиция комитеты әгъзасына шәхси имзасы куелып тапшырыла.

Бюллетеньдә бюллетеньне кабул итү вакыты, аны җибәрергә кирәк булган урын, көн тәртибе, тавыш бирүгә куелган сораулар, алар буенча карарлар проектлары беркетелә.

Инвестиция комитеты тарафыннан читтән торып тавыш бирү рәвешендә кабул ителгән карарлар читтән торып тавыш бирү турында хәбәрнамә өчен каралган тәртиптә читтән торып тавыш бирү нәтиҗәләре хакында беркетмә төзегәннән соң биш календарь көненнән дә соңга калмый тавыш бирү йомгаклары турында хисап рәвешендә Инвестиция комитеты әгъзаларына җиткерелә.

8.12. Инвестиция комитеты утырышында беркетмә алып барыла.

Беркетмә шулай ук читтән торып тавыш бирү нәтиҗәләре буенча төзелә. Инвестиция комитеты утырышы беркетмәсе (читтән торып тавыш бирү нәтиҗәләре турында беркетмә) утырышта рәислек итүче (Инвестиция комитеты рәисе) һәм беркетмәнең дөрес төзелүе өчен җаваплы Инвестиция комитеты секретаре тарафыннан имзалана. Инвестиция комитеты утырышы беркетмәсе (читтән торып тавыш бирү нәтиҗәләре турында беркетмә) аны үткәргәннән (бюллетеньнәр кабул итү вакыты тәмамланганнан) соң өч календарь көннән дә соңга калмый төзелә. Беркетмәләр Фондта саклана. Инвестиция комитеты әгъзалары бюллетеньнәре беркетмәгә теркәлә һәм аның аерылгысыз өлеше була.

8.13. Фондның бер затлы башкарма органы директор була. Директорны вазыйфасына Совет билгели һәм вазыйфасыннан Совет азат итә. Директорның вәкаләтләре вакыты биш ел.

8.14. Директор:

дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, чит дәүләтләр оешмалары һәм халыкара оешмалар, башка оешмалар белән мөнәсәбәттә Фонд исеменнән ышанычнамәсез эш итә һәм ышанычнамәсез Фондның мәнфәгатьләрен күрсәтә;

Фондның коллегиаль башкарма органын – Инвестиция комитетын җитәкли һәм Совет секретаре булып тора, Фонд органнары карарларын тормышка ашыруны оештыра;

Фонд эшчәнлеге мәсьәләләре буенча боерыклар һәм әмерләр чыгара;

Фонд хезмәткәрләрен вазыйфаларына билгели, күчерә һәм вазыйфаларыннан

азат итә, бүләкләү чаралары күрә һәм дисциплинар җәзалар бирә;

Фондның локаль норматив актларын, шул исәптән Фондның оештыру-функциональ структурасын һәм штат расписаниесен раслый;

Совет яки Инвестиция комитетының расланган карарлары нигезендә Фонд мөлкәте һәм акчасы белән идарә итә, Совет һәм Инвестиция комитеты күрсәтмәләрен үтәүне оештыра;

Фонд исеменнән ышанычнамәләр бирә, шул исәптән бер кешедән икенче кешегә бирү хокукы булган ышанычнамәләр;

Совет хуплавын алмыйча гына бәясе Фонд активларының соңгы хисап датасына бухгалтер хисаплыгы мәгълүматлары буенча билгеләнгән баланс кыйммәтенең 10 проценттан артмаган өлешен тәшкил иткән проектларга инвестицияләү буенча килешүләр яки берничә үзара бәйләнгән килешүләр төзи;

Фонд алдында торган бурычларны хәл итүгә юнәлдерелгән һәм әлеге Устав белән Попечительләр советы, Совет яки Инвестиция комитеты компетенцияләренә кертелмәгән бүтән гамәлләр кыла.

## 9. Мәнфәгатьләр каршылыгы һәм җаваплылык

9.1. Фондның «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның 27 статья нигезендә мәнфәгатьле дип танылган мәнфәгатьле затлары Фонд мәнфәгатьләрен, иң беренче чиратта аның эшчәнлеге максатларына мөнәсәбәттә, сакларга тиеш, һәм Фонд мөмкинлекләрен фонд Уставында каралганнардан башка максатларда файдаланырга яки файдалануын рөхсәт итәргә тиеш түгел.

9.2. Фонд исеменнән чыгыш ясау вәкаләтләре бирелгән затлар, шулай ук Фондның коллегиаль органнары әгъзалары Фонд, аның Фонд мәнфәгатьләрендә чыгыш ясаучы Гамәлгә куючысы таләбе буенча үз гаепләре белән фондка китерелгән зыянны Россия Федерациясе Гражданнар кодексының $53^1$ статьясы нигезендә тулысынча капларга тиешләр.

Фонд исеменнән чыгыш ясарга вәкаләтле затлар, әгәр үз хокукларын гамәлгә ашырганда һәм үз вазыйфаларын башкарганда алар намуссыз һәм акылсыз эш итсәләр, шул исәптән аларның гамәлләре (гамәл кылмаулары) граждан әйләнешенең гади шартларына яки гади эшмәкәрлек куркынычына туры килмәсә, Россия Федерациясе Гражданнар кодексының $53^1$ статьясы нигезендә җавап тота.

9.3. Фондның коллегиаль органнары әгъзалары, әгәр Фондка зыян килүгә китергән карарга каршы тавыш бирсәләр яки намуслы эш итеп, тавыш бирүдә катнашмасалар, Россия Федерациясе Гражданнар кодексының $53^1$ статьясы нигезендә җавап тотмый.

9.4. Фондның гамәлләрен фактта билгели алу мөмкинлеге булган, шул исәптән әлеге Уставның 9.2 пунктында күрсәтелгән затларга күрсәтмәләр бирү мөмкинлеге булган затлар Фонд мәнфәгатьләрендә акыл белән һәм намуслы эш итәргә тиеш һәм үзе гаебе белән Фондка китерелгән зыяннар өчен җавап тота.

9.5. Фондка бергәләп зыян китергән очракта, әлеге Уставның 9.2 һәм 9.4 пунктларында күрсәтелгән затлар аларны бергәләп кире кайтарырга тиеш.

## 10. Исәп һәм хисаплылык

10.1. Фонд билгеләнгән тәртиптә бухгалтер исәбен алып бара, Фондның бухгалтер (финанс) һәм статистика хисаплылыгын төзи һәм аларның дөреслеге өчен законнар нигезендә җавап тота.

10.2. Фонд эшчәнлегенең финанс елы календарь елы белән туры килә.

## 11. Фондны яңадан оештыру һәм ябу

11.1. Фондны яңадан оештыру рөхсәт ителми.

11.2. Фонд уставы түбәндәгеләр карары белән үзгәртелергә мөмкин:

Фондны гамәлгә куючы;

әгәр Фонд Уставын үзгәрешсез рәвештә саклау Фондны гамәлгә куйганда алдан белү мөмкин булмаган нәтиҗәләргә китерчәк, ә Фондны Гамәлгә куючы аны үзгәртмәгән очракта, Фонд органнары яки Фонд эшчәнлегенә күзәтчелекне гамәлгә ашырырга вәкаләтле дәүләт органы гаризасы белән кабул ителгән суд.

11.3. Фонд бары тик мәнфәгатьле затлар гаризасы белән кабул ителгән суд карары нигезендә генә ябылырга мөмкин:

әгәр Фонд мөлкәте аның максатларын гамәлгә ашыру өчен җитәрлек булмаса һәм зарур мөлкәтне алу мөмкинлеге реаль булмаса;

Фонд максатлары ирешелә алмаса, ә Фонд максатларын кирәк булганча үзгәртү мөмкин булмаса;

үз эшчәнлегендә Фонд әлеге Уставта каралган максатлардан тайпылса;

федераль законнарда каралган башка очракларда.

11.4. Фондны япканда аның кредиторлар таләпләрен канәгатьләндергәннән соң калган мөлкәте әлеге Устав нигезендә аларга ирешү өчен Фонд төзелгән максатларга юнәлдерелә. Әгәр мөлкәтне әлеге Устав нигезендә куллану мөмкин булмаган очракта, ул дәүләт кеременә кушыла.

---

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2004 ел, 17 ноябрь, 498 нче
карары белән расланды

**«Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешманың югары коллегиаль органы – Совет составы**

| | |
|---|---|
| Халиков Илдар Шәүкәт улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры, Совет рәисе |
| Айдельдинов Айнур Тәүфикъ улы | «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешма директоры (килешү буенча) |
| Борһанов Рәфис Тимерхан улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшмәкәрлек комитеты рәисе (килешү буенча) |
| Гайнетдинов Ренат Вәгыйз улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Икътисад, финанслар һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе башлыгы |
| Гәрәев Зөфәр Фәнил улы | «Ак Барс» Банк ГАҖ идарәсе рәисе (килешү буенча) |
| Гафуров Илшат Рәфкать улы | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белемнең федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Гыйлметдинов Альберт Харис улы | «А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ» югары белемнең федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Даутова Евгения Валентиновна | «Спурт» акционер коммерция банкы» ГАҖ Идарәсе рәисе (килешү буенча) |
| Дьяконов Герман Сергеевич | «Казан милли тикшеренү технология университеты» югары белемнең федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Здунов Артём Алексеевич | Татарстан Республикасы икътисад министры |

| | |
|---|---|
| Кәримов Альберт Әнвәр улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры |
| Миңнуллина Талия Илгиз кызы | Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе |
| Нәфыйгин Альберт Илдар улы | Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе (килешү буенча) |
| Сафиуллин Илсур Миңнур улы | Татарстан Республикасы Премьер-министрының икътисад мәсьәләләре буенча киңәшчесе |
| Фәйзрахманов Марат Җәүдәт улы | Татарстан Республикасы финанс министрының беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты директоры |
| Фәттахов Энгель Нәвап улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |
| Шәйхетдинов Роман Александр улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры |
| Йосыпов Камил Раиф улы | «Аверс» банкы ЖЧЖ Идарәсе рәисе (килешү буенча) |
| Яруллин Рафинат Самат улы | «Татнефтехиминвест-холдинг» ААҖ генераль директоры (килешү буенча). |

______________________________

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 ел, 17 ноябрь, 498 нче карары белән расланды
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 11 февраль, 83 нче карары редакциясендә)

**«Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешманың Попечительләр советы составы**

| | |
|---|---|
| Миңнеханов Рөстәм Нургали улы | Татарстан Республикасы Президенты, Попечительләр советы рәисе (килешү буенча) |
| Гайзатуллин Радик Рәүф улы | Татарстан Республикасы финанс министры, Попечительләр советы рәисе урынбасары |
| Агамирзян Игорь Рубенович | «Россия венчур компаниясе» ААҖ генераль директоры – Идарә рәисе (килешү буенча) |
| Агеев Шамил Рәхим улы | Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы Идарәсе рәисе (килешү буенча) |
| Варданян Рубен Карленович | «Варданян, Бройтман һәм партнерлар» ҖЧҖ гамәлгә куючысы – партнер (килешү буенча) |
| Галицкий Александр Владимирович | Almaz Capital Partners венчур фонды җитәкчесе, «Элвис-плюс» компаниясе президенты (килешү буенча) |
| Джонсон Александра | «DFJ VTB «Аврора» Фонды идарәче директоры (килешү буенча) |
| Комиссаров Алексей Геннадиевич | «Сәнәгатьне үстерү фонды» дәүләт учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Сәләхов Мәгъсүм Хәлимулла улы | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт казна бюджет учреждениесе президенты (килешү буенча) |
| Шаронов Андрей Владимирович | «СКОЛКОВО» Мәскәү идарә мәктәбе ректоры, Мәскәү шәһәре мэры киңәшчесе (килешү буенча). |

---